

Совет халкынын Боек Ватан сугышында Жинvенә 75 ел тулу белән бәйле истәлекле дата якынайганнан- якыная бара. Мордовиядә әлеге дата алдыннан «Мордовия халкы - Ватан Геройлары» проектына старт бирелде. Проект Мемориальный музей военного и трудового подвига 1941-1945 гг. тәкъдим ителде.     Мордовия Икенче ботендонья сугышында фашист Германиясен тар-мар итvгә зур олеш кертте, - дип сойләде музейнын фәнни пропаганда бvлеге модире Анастасия Крыгина. - Беренче ике айда ук Мордовиядә туып-vскән 6 меннән артык кеше ирекле рәвештә фронтка китте. Сугыш елларында безнен республикадан 249 меннән артык кеше сугышка киткән, аларнын 133 меннән артыгы һәлак булган, яралардан vлгән, хәбәрсез югалган. Йоз менгә якын сугышчы һәм командир сугышларда кvрсәткән батырлыклары очен орден һәм медальләр белән бvләкләнгән. Йоздән артык якташыбыз Советлар Союзы Герое, 29 кеше - Дан орденынын тулы кавалерлары исеменә лаек булган».

«Мордовия халкы - Ватан Геройлары» проекты кысаларында бик кvп патриотик чаралар узачак. Алар 2019 елнын беренче октябрендә старт алачак һәм 2020 ел ахырына кадәр дәвам итәчәк.

Музейларда партизаннар хәрәкә-тенә, мобилизациягә, концлагерь тоткыннарына, полководецларга, хәрби башлыкларга, Дан орденынын тулы кавалерларына, фронттагы шагый-рьләргә һәм язучыларга багышланган тематик экскурсияләр узачак. «Мордовия - Боек Жинvгә», «Фронт портреты», «Бvләкләр һәм батырлыклар», «Жинv китап елъязмасы» һ.б. кvргәзмәләр узачак. Проект кысаларында «Солдат язмышын ачыкла» дигән солдат язмышларын билгеләv буенча эш дәвам итәчәк. Мәгариф идарәсе белән берлектә шәһәр мәктәпләрендә Россиянен Хәрби дан коннәренә, Боек Ватан сугышынын топ вакыйгаларына багышланган «Батырлык дәресләре» vткәреләчәк. Боек Жинvнен 75 еллыгына багышлап «Все звучит во мне его песня…» дигән патриотик жырлар фестивале дә vткәреләчәк…»